**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

16 апрель 2024ел № 224

**Әтнә муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты» 2023 елның 14 декабрендәге 207 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Әтнә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И. Гыймадиев докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Әтнә муниципаль район Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты» 2023 елның 14 декабрендәге 207 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. 2024 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 630642,1 мең сум;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 647376,9 мең сум;

в) Әтнә муниципаль районының бюджет дефициты 16734,8 мең сум.»

2) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 1 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

3) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 2 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

4) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 3 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

5) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 4 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 4 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

6) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 5 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 5 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

7) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 9 нчы кушымтаның 1 нче таблицасын 9 нчы кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әтнә районы Башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарларын расларга:
№147 22.02.2024ел.; №162 01.03.2024ел.; №186 18.03.2024ел.; №189 22.03.2024ел.

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Г.Г. Хәкимов